**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 1 апрель № 203

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәгълүмат технологияләре өлкәсендәге кече эшмәкәрлек субъектларын бизнес-инкубацияләү» дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын раслау турында» 2014 ел, 26 май, 352 нче карары белән расланган «Мәгълүмат технологияләре өлкәсендәге кече эшмәкәрлек субъектларын бизнес-инкубацияләү» дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәгълүмат технологияләре өлкәсендәге кече эшмәкәрлек субъектларын бизнес-инкубацияләү» дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын раслау турында» 2014 ел, 26 май, 352 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 27 октябрь, 788 нче; 2014 ел, 29 декабрь, 1055 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Мәгълүмат технологияләре өлкәсендәге кече эшмәкәрлек субъектларын бизнес-инкубацияләү» дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 бүлектә:

4.5.3 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Менторларны, экспертларны һәм компетентлы башка затларны җәлеп итү чыгымнары бизнес-инкубацияләү хезмәтләре күрсәтүгә норматив чыгымнар нигезендә бүлеп бирелгән акча хисабына гамәлгә ашырыла.»;

Бизнес-инкубатор резиденты статусын алуга проектлар сайлап алу тәртибендә:

8.2 нче пунктның беренче абзацына түбәндәге эчтәлекле җөмләләр өстәргә:

«Сайлап алуның икенче этабына бизнес-инкубатор резиденты статусын алуга

дәгъва итүчеләр һәм экспертлар турыдан-туры катнашу өчен чакырыла. Экспертлар җәлеп итү чыгымнары бизнес-инкубацияләү хезмәтләре күрсәтүгә норматив чыгымнар нигезендә бүлеп бирелгән акча хисабына гамәлгә ашырыла.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин

F:\KARAR\2015\203.doc